**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт, Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.r

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

___________ № ___________

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Иске Айман төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең «Иске Айман балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе структур бүлекчәсен бетерү турында**

Россия Федерациясе Граждан кодексының 61-64 статьяларына, «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясына, «Россия Федерациясендә мәгариф турында**»** 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктына таянып, Актаныш муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яисә бетерү турында карар кабул итүнең нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясенең 2022 елның 31 августындагы 28 номерлы бәяләмәсе, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының 2022 елның 10 августындагы Иске Айман авылы гражданнар җыелышы протоколы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Иске Айман төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең «Иске Айман балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе структур бүлекчәсен 2022 елның 1 сентябреннән бетерергә.

2. «Иске Айман төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры А.А.Насыйровага:

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Иске Айман төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе уставына үзгәреш проектын әзерләргә;
- хезмәт законнары нигезендә бетерелә торган мәгариф учреждениесе штатларын кыскарту процедурасын үткәрүне тәэмин итәргә;
- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Иске Айман төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең «Иске Айман балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе структур бүлекчәсен законда билгеләнгән тәртиптә бетерергә.

3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Р.М. Шакировага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.А.Ильясов